**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 8 сентябреннән № 12-81

2025 елда «2025-2030 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2026 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.К. Исхакова 2025 елда 2025-2030 елларда Яңа Чишмә муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2026 елга бурычлары турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда 2025-2030 елларда Яңа Чишмә муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2026 елга бурычлары турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. расланган максатчан индикаторларга һичшиксез ирешүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын кулланып, барлык программа чараларын вакытында һәм тулы күләмдә гамәлгә ашыруны гарантияләргә;

2.2. бизнес булдыруның һәм эшчәнлегенең барлык этапларында муниципаль хезмәтләрдән максималь файдалануны тәэмин итә торган цифрлы инструментларны һәм онлайн-сервисларны актив кертеп, эшкуарлар җәмәгатьчелеге өчен мәгълүмати-консультация һәм хокукый хезмәтләр исемлеген эзлекле рәвештә арттырырга;

2.3. эшкуарлар һәм үзмәшгуль гражданнар белән аларны укыту һәм электрон мәйданчыкларга һәм маркетплейсларга чыкканда методик ярдәм күрсәтү, шулай ук интернет-сатуларны үстерү һәм товарларны танып белүне арттыру максатында республика маркетинг үзәге (шул исәптән «Биржа мәйданчыгы» сервисы) инструментларын актив куллану өлешендә планлы хезмәттәшлекне җайга салырга;

2.4. бизнес-бергәлек өчен дәүләт ярдәменең барлык актуаль чараларын (федераль, төбәк һәм җирле), грант мөмкинлекләрен, ташламалы финанслау программаларын һәм укыту проектларын өзлексез һәм вакытында яктыртуны тәэмин итәргә, материалларны һәркем файдалана алырлык барлык интернет-мәйданчыкларда даими бастырып чыгарырга һәм мәгълүмати семинарлар оештырырга;

2.5. буш җир кишәрлекләрен һәм буш җитештерү мәйданнарын икътисадый әйләнешкә кайтаруга, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен заманча инновацион, склад һәм кооперация мәйданчыклары булдыруга аерым игътибар биреп, эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын булдыру һәм ныгыту эшчәнлеген активлаштырырга;

2.6. җирле хезмәт базарының динамикасын даими күзәтеп торырга, эшкә урнашуга һәм мәшгульлекне саклауга ярдәм итүнең максатчан чараларын эшләп һәм гамәлгә кертеп, вакытлыча эшләрне һәм һөнәри әзерлек программаларын оештыруны да кертеп, район халкына мәгълүмати, методик һәм консультацион ярдәм күрсәтеп, эш бирүчеләрнең кадрлар таләпләрен һәм эш эзләүчеләрнең мөмкинлекләрен системалы рәвештә өйрәнергә;

2.7. төбәкләрнең һәм муниципалитетларның эшлекле климатны яхшыртуга, бизнес ачу һәм алып бару өчен кирәкле административ процедураларны һәм срокларны кыскартуга юнәлдерелгән иң яхшы тәҗрибәләрен кертеп, Россия инвесторлары арасында районның инвестицион мөмкинлекләрен алга җибәрү буенча эшне активлаштырырга;

2.8. сәнәгать мәйданчыгына яңа резидентлар җәлеп итү чараларын дәвам итәргә, гамәлдәге резидентларга комплекслы ярдәм күрсәтергә, шул исәптән үз продукцияләрен Россия эчендә дә, аннан читтә дә сату базарларын киңәйтү өчен маркетинг һәм күргәзмә чараларын оештыруда һәм уздыруда ярдәм итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский